НОМЕРДА – ДОКУМЕНТ

Татарстан Республикасы законнары

> 3

ЯЗУ ҺӘМ СЫЗУ

Танылган журналист Илсөяр Хәйруллина «Ватаным Татарстан»да эшләгән елларын искә ала

> 3



ЗАРЛАНАСЫ КИЛӘ!

Россиядә психологка мөрәҗәгать итүчеләр саны 7 процентка арткан

> 4

ЮБИЛЕЙ БӘЙГЕСЕ

Муса Җәлил истәлегенә газетабыз гамәлгә куйган турнирның 60нчысы узачак

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 18 (28985) | Сишәмбе | 7 февраль | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

АШАГАН БЕЛМИ, ЭШЛӘГӘН БЕЛӘ

«Татар-информ»

Яшәеш

Берәүләр өйдә токмач баса, икенчеләр исә таксист булып йөри. Быел илдә төп эшләреннән кала, өстәмә акча эшләүчеләр саны 30 процентка арткан. Белгечләр әйтүенчә, халык шул рәвешле матди хәлен азмы-күпме кайгыртырга тырыша. «ВТ» хәбәрчесе буш вакытларында акча эшләүчеләрнең хәлен белеште.

Ләйсән Хәкимова башкаладагы мәктәпләрнең берсендә математика һәм информатика укытучысы булып эшли. Балаларга белем бирүдән тыш, яллар-да чүпрәсез ипи пешереп сата ул.

– Фатирыбыз да, мин йөри торган машина да – кредитта. Ике балабыз бар. Гаиләдә акчаның җитәсе юк. Шуңа күрә буш вакытымда бөртекле оннан чүпрәсез ипи пешереп сатам. Хуҗабикәләр өчен моның әллә ни кыенлыгы юк. Хәзер күпчелек сәламәт яшәү рәвеше алып барырга тырыша. Шуңа күрә мин пешергән ризыкка ихтыяҗ зур. Бер түгәрәк ипи 350–400 сум тора. Атнасына сигез-унны пешергән чаклар да бар. Икмәк өчен иң элек оеткы әзерлим. Аны алты көн дәвамында көн саен бер үк вакытта «ашатырга», ягъни он һәм су өстәп торырга кирәк. Оеткыны җылы, караңгы урында саклыйм. Ул анда үсә, кабара. Җиденче көндә шул оеткыдан ипи басам. Аның исе бөтен фатирга тарала. Камыр ризыгын җылы килеш алып бетерәләр. Икмәкне багет кебек юка, озынча итеп тә пешерәм, анысының бәясе 250 сумнан башлана, – ди Ләйсән Хәкимова.

SuperJob порталы үткәргән сораштыру нәтиҗәләренә караганда, илдә яшәүчеләрнең 30 процентының өстәмә эш урыны бар. «Бер генә урында эшләү белән чикләнмим», – дип җавап бирүчеләрнең 22 проценты өчен бу өстәмә керем чыганагы булып тора. Ә калганнар өстәмә эш урынына тагын да зуррак өметләр баглап, киләчәктә әнә шул хезмәт юлыннан китмәкче. Болай фикер йөртүчеләр арасында хәзерге эш урыныннан риза булмаучылар да, өйдә эшләү яки үз вакытыңа үзең хуҗа булып йөрү күбрәк ошый, дип әйтүчеләр дә җитәрлек. Өстәмә эш башкаручылар төзелеш, көнкүреш хезмәтләре күрсәтү һәм белем бирү тармакларында күбрәк икән. Мондый эшкә атнасына уртача ун сәгать вакыт китә. Ул гаилә кеременең 30 процентына кадәр табыш китерә. Өстәмә эшне 40 яшькә кадәргеләр һәм хатын-кызлар күбрәк эзли. Чагыштыру өчен: узган ел башында берьюлы берничә эштә тир түгүчеләр 20 процентка да тулмаган.

Өстәмә эш эзләүчеләр арасында хатын-кызлар күбрәк булуына гаҗәпләнәсе юк, ди психолог Венера Касыймова.

– Пешерү, тегү, бала карау дисеңме, өстәмә керем чыганагы була алырлык эшләрнең күбесе нәкъ менә гүзәл затларга туры килә. Хатын-кызларга даими эш урыны табу да кыенрак. Ирләр белән чагыштырганда, алар азрак хезмәт хакы алып эшли. Шуңа күрә өстәмә эшкә тизрәк ризалашалар, – ди белгеч.

Белдерүләр сайтларының берсенә кереп, өйдә баскан токмач эзләп карадык. Казанда гына да утыздан артык игълан чыкты. Токмачны авыл йомыркасы һәм югары сортлы оннан гына басалар әнә. Бер кило токмач бәясе уртача 500 сумнан башлана. Гүзәл затлар бер-берсен уздырып эшли. Мәсәлән, балаларга укроп суы кушылган яшел токмач яки аллергиядән интегүчеләргә бүдәнә йомыркасыннан әзерләнгән токмач та сайлап алырга мөмкин.

Лаешта яшәүче Динар Сафин буш вакытларында такси хезмәтендә эшли. Яңа машина да сатып алырга туры килгән хәтта.

– Хатыным кечкенә бала белән өйдә утыра, – ди ул. – Өч кеше өчен берүзем эшлим. Төп эш урыным документ эшенә бәйле. Рульдә йөргәндә башны да ял иттерәм бераз. Таксида ял көннәрендә һәм кичләрен йөрим. Акчасы күпме эшләүгә бәйле, әлбәттә. Ял көннәрендә, мәсәлән, ярты көн эшләсәм, кесәгә 4–5 мең сум акча керә. Заказларны кесә телефонындагы кушымта аша кабул итәм. Әле былтыр гына эш өчен үзебездә җитештерелгән яңа машина сатып алдым. Кушымтада яңа автомобильләрнең рейтингы зуррак, ягъни сиңа кыйммәтлерәк заказлар күбрәк килә. Атнага 120 заказ үтәргә кирәк. Планны тутырсаң, ике мең сум тирәсе акча өстәп түлиләр. Такси хуҗалары үзмәшгуль буларак теркәлергә дә тәкъдим итә. Таксида йөрүчеләр арасында андыйлар күп. Тик бу хакта ныклап уйлаганым юк әле.

«Работа.ру» сервисы генераль директоры урынбасары Александр Ветерков фикеренчә, үзмәшгульлек гамәлгә керү өстәмә эшкә бәйле кызыксынуны арттырды. Өстәвенә һөнәри керемгә салым түләүчеләр хәзер берьюлы берничә хезмәт башкарулары турында курыкмыйча әйтә ала. Билгеле булганча, үзмәшгульләргә махсус кагыйдәләр илнең берничә төбәгендә, шул исәптән Татарстанда 2019 елдан бирле гамәлдә. Керемгә салым күләме 4 яки 6 процент тәшкил итә. 2022 ел азагына алынган мәгълүматларга караганда, республикада 230 мең үзмәшгуль теркәлгән. Программа эшли башлаганнан бирле алар 73 миллиард сумга якын керем алган.

Ирекле баштан беркем дә салым йөген тартырга керешми, билгеле. Икътисад белгече Илдус Сафиуллин сүзләренә караганда, халыкның кесә ягы такырая. Шуңа күрә халык матди хәлен азмы-күпме яхшыртырга тырыша.

– Узган ел ахырында илнең 70тән артык төбәгендә халыкның реаль керем дәрәҗәсе кимү күзәтелде. Хәзер әлеге күрсәткеч уртача 3 процент чамасы тәшкил итә. Моңа аптырыйсы да юк, былтыр яз көне бәяләр, шул исәптән азык-төлекнеке дә кискен кыйммәтләнде. Ә хезмәт хаклары шул ук. Илдә эшсезлек дәрәҗәсе дә кимеми. Шуңа күрә илдә яшәүчеләр, бигрәк тә яшьләр һәм яшь гаиләләр берничә урында эшләргә мәҗбүр.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Яңа җитәкче

Татарстан Рәисе Указы белән, республика сәламәтлек саклау министры вазыйфаларын башкаручы итеп Марсель Миңнуллин билгеләнде. Ул 2010 елдан башлап хәзергә кадәр Республика клиник хастаханәсе баш табибының беренче урынбасары булып эшләгән. Министрлык коллективын яңа җитәкче белән Премьер-министр Алексей Песошин таныштырды.

Марсель Миңнуллин 1974 елда Казанда туган. 1997 елда Казан дәүләт медицина университетының дәвалау факультетын, шуннан соң № 1 хирургия авырулары кафедрасында клиник ординатура тәмамлаган. Һөнәри эшчәнлеген Казанның 5 нче шәһәр хастаханәсендә эренле хирургия бүлегендә башлап җибәргән. 2004 елда КГМУның хирургия авырулары кафедрасында кандидатлык диссертациясе яклаган.

Исегезгә төшерәбез: Татарстан сәламәтлек саклау министры Марат Садыйковны соңгы юлга узган атнада озаттылар. Ул 54 нче яшендә арабыздан мәңгегә китте.

Метро төзелеше тукталмый

Казан метросының икенче тармагының «Фучик»тан «Сахаров» станциясенә кадәрге беренче өлешен төзүгә республика бюджетыннан 926,6 миллион сум биреләчәк. Эшчеләргә җир астында ярты чакрым диярлек озынлыктагы сул һәм уң як юлларны, шуның кадәр үк озынлыкта чигенү юлларын салырга кирәк булачак. Эшләр 30 ноябрьгә кадәр башкарылырга тиеш.

Проектның заказчысы – Главстрой идарәсе. Ул төзүчеләрдән 13 февральгә кадәр заявкалар кабул итеп, 15 февральдә җир асты юлын кем салачагын билгеләячәк.

Узган елда Казан метросының икенче тармагын төзүгә чама белән 1,5 миллиард сум тотылган. Гомумән алганда, яңа тармакның беренче өлешен төзүгә барлыгы 41 миллиард сумнан артыграк акча кирәк булачак.

Исегезгә төшерәбез: метроның икенче тармагы Киров, Мәскәү, Яңа Савин, Идел буе һәм Совет районнары аша узып, «Яшьлек» һәм «Имәнлек» станцияләрендә метроның беренче линиясенә килеп тоташачак. Аның беренче өлешен 2027 елда файдалануга тапшыру күздә тотыла.

Борчыган мәсьәлә

Тукталышта да сагалый

МОШЕННИКЛАР ХАЛЫКНЫ АЛДАУНЫҢ ЯҢА ЫСУЛЫН УЙЛАП ТАПКАН

QR-код аша кер дә социаль түләүгә ия бул! Соңгы арада мошенниклар халыкны төп башына утыртуның яңа ысулын уйлап тапкан. Җәмәгать урыннарына шундый эчтәлектәге игъланнар урнаштыра башлаган алар. Мондый ялган игъланнар күбрәк транспортта, тукталышларда, подъезд төбе, машина кую урыннарында очрый, дип кисәтә белгечләр.

Белдерүдә күрсәтелгән QR-кодка бассаң, белгечләр, бушлай консультация уздырып, сиңа тиешле социаль түләүне рәсмиләштерергә ярдәм итәчәк, имеш. Кырыгалдарлар балалы гаиләләргә, студентларга – кыскасы, кемгә социаль ярдәм кирәк, шуларга пособие рәсмиләштерергә «булышмакчы». Россия Үзәк банкы рәисе урынбасары Герман Зубарев сүзләренә караганда, мошенниклар бу очракта шактый оста эшли.

– QR-код рәсеменә баскач, кеше автомат рәвештә барыбызга билгеле мессенджердагы махсус чатка килеп эләгә. Соңгы арада мондый бот-чатлар аеруча популяр бит. Шуңа күрә кеше үзен ведомствоның рәсми чатына килеп эләккән кебек хис итә. Алга таба биредәге робот-белгеч, сорау арты сорау биреп, аннан барлык кирәкле мәгълүматны җыеп ала. Хәтта кешенең банк картасына да юл ачыла. Шул рәвешле ул бар булган акчасыннан колак кагарга мөмкин, – дип кисәтә Герман Зубарев.

Хокук сакчылары да мондый шикле игъланнарны урап узарга киңәш итә. «Кеше күп йөри торган урыннардагы юк-бар язуларга бигрәк тә шикләнеп карарга кирәк. Рәсми оешмалар беркайчан да мондый алымнар белән эш итмәячәк», – ди белгечләр.

Мошенникларның алдау алымнары исә гел үзгәреп тора. Хәтерләсәгез, әле күптән түгел генә алар: «Мобилизациянең яңа дулкыны булачак. Якыныңның анда эләгәчәк ир-егетләр исемлегендә бармы-юкмы икәнлеген тиз арада ачыкларга ярдәм итәм», – ише игъланнар белән халык арасында коткы тараткан иде. Юрист Илнур Галимуллин сүзләренә караганда, соңгы арада кырыгалдарлар телефон аша алдауның да икенче бер юлын тапкан. Алар, өч-дүрт көн аерма белән даими рәвештә шалтыратып, иң элек кешенең ышанычын яуларга тырыша икән.

– Беренче шалтыратуында алар, гадәттә, кеше турында шәхси мәгълүмат тупларга тырыша. Икенче шалтыратканда, үзен банк хезмәткәре дип таныштырып: «Сезнең картадан әле генә фәлән сум акча салдырдылар. Моны сез эшләдегезме, әллә башка кешеме?» – дип сорап, «юк» дигән җавап ишеткәч, җайлап кына трубкасын куя. Өченче тапкыр шул ук банкның сак хезмәткәре буларак шалтыратып, соңгы арада мошенниклар активлашты, сак булыгыз, дип кисәтергә мөмкин. Өч тапкыр кешенең башын әйләндерә торгач, дүртенче шалтыратканда инде ул аны һичшиксез төп башына утыртачак. Шуңа күрә бер-бер артлы мондый шалтыратулар килә башласа, иң элек моның нинди хәл икәнен банкның үзеннән шалтыратып белешегез, – дип киңәш итә белгеч.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сүзгә-сүз

Антон СИЛУАНОВ, Россиянең финанс министры:

Доллар, евро, фунт һәм башкалар төп исәп-хисап берәмлекләре булып саналды. Әмма вазгыять аларның ышанычсыз, теләсә кайчан юкка чыгарылырга мөмкин икәнен күрсәтте.

(«Беренче канал»га әңгәмәсеннән)

РОССИЯ КАЛАЛАРЫНДА – ҺАВА ТОРЫШЫ

«Яндекс Погода» белгечләре халык саны 1 миллион кешедән арткан Россия шәһәрләрендә февраль аенда уртача һава температурасын исәпләп чыгарган. Соңгы 10 елда Красноярск – иң суык урын, Краснодар исә иң җылысы булып чыккан.

Шәһәр	Уртача температура	Шәһәр	Уртача температура
Красноярск	–14,6°	Казан	–8,2°
Омск	–14,3°	Түбән Новгород	–6,7°
Новосибирск	–13,7°	Мәскәү	–4,4°
Чиләбе	–11,5°	Воронеж	–3,9°
Екатеринбург	–10,5°	Санкт-Петербург	–3,5°
Пермь	–9,7°	Волгоград	–3,4°
Уфа	–9,4°	Ростов-Дон	–0,1°
Самара	–8,4°	Краснодар	+3,4°

Машина җитми

Гыйнвар аенда Россиядә җиңел машиналар узган елның шушы ук чорындагыга караганда 63,1 процентка кимрәк сатылган. Гадәттә елның беренче аенда алар болай да аз сатыла, ләкин быел бу хәл иң элек илдә автомобиль кытлыгына бәйле.

«Комерсантъ» хәбәренә караганда, Lada иң популяр машина булып кала: ул узган елдагыдан 3 процентка гына азрак сатылган (7,5 мең). Гомумән, гыйнварда үз хуҗасын тапкан машиналарның 53,7 проценты – АвтоВАЗныкы. Икенче урында – Haval (43 процентка кимегән – 4,5 мең). Кризис башланганнан бирле Россиядә җитештерүне дәвам иткән бердәнбер чит ил бренды бу. Өченче урында Кытайның тагын бер маркасы – Geely. Бу машинаны сату 88 процентка арткан (3,5 меңгә җиткән).

Үзебезнең ГАЗга килсәк, ул 32 процентка кимрәк сатылган (1,8 мең данә). Ә Kia – 89 процентка (1,4 мең).

Кыш үзенекен итә

Бу атнада Татарстанда суыта. Гидрометеоүзәк мәгълүматларына караганда, төнлә һава температурасы 27 градуска кадәр төшәргә мөмкин. Чәршәмбе – 8 февральдә көндез –8…–13 градус булыр дип көтелә. Төнлә һәм иртән термометрның терекөмеш баганасы –17…–22, урыны белән –27 градус күрсәтәчәк. Явым-төшем ихтималы аз. Кайбер районнарда томан төшүе бар. Пәнҗешәмбе – 9 февральдә көндез –3…–8 градус булачак. Кар явачак. Төнлә –9…–14, көньяк районнарда 18 градуска кадәр салкын.

Синоптикларның башлангыч фаразларына караганда, җомга һәм шимбә – 10–11 февральдә явым-төшем көтелми диярлек. Көндез һава температурасы –3…–9 градус чикләрендә тирбәләчәк. Төнлә –10…–15, урыны белән 19 градуска кадәр салкын булачак.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

АМЕРИКАНЫ КУРКЫТКАН ШАР

Яңа атнаның беренче көне Төркиядән фаҗигале хәбәр белән башланды. Таң алдыннан, сәхәр вакытында, Кахраманмарашта – илнең көньяк-көнчыгышында урнашкан шәһәрдә 7,4 баллы магнитудалы җир тетрәү булды. Газета хәбәрчесе телефонына һәлакәтнең беренче кадрлары сурәтләнгән роликлар килгәндә, әле фаҗигагә бер сәгать тә булмаган иде. Җир тетрәү башка провинцияләргә дә җәелде. Биналар Адыяманда, Килиста, Шанлыурфада, Диярбакырда, Аданда һәм тагын берничә шәһәрдә җимерелде. Бу юллар язылганда, исәпкә алынган корбаннар саны 1000нән артып китте. Эчке эшләр министры: «Без дүртенче дәрәҗәдә тревога игълан иттек. Бу – халыкара ярдәм сорый торган сигнал», – диде. Бу – соңгы сигез елда Төркиядәге өченче шундый куркыныч җир тетрәү.

Бәлагә тарыганда дәүләтләрнең үзара ярдәмләшүләре табигый. Кызганыч, соңгы вакытларда илләр үзара хезмәттәшлек сукмагыннан чыгып, тарткалашу һәм хәрби конфликтлар юлына баса башлады. Үткән атнаның төп интригаларыннан берсе Америка өстендәге Кытай зонды булды. Һава шары АКШ күгенә 28 гыйнварда ук үтеп кергән икән, мәгълүмат кырына аның турындагы хәбәрләр пәнҗешәмбе көнне генә чыга башлады. Пекин аэростатны курстан тайпылган гадәти метеозонд кына дип тынычландырырга тырышты. Әмма Вашингтонда моңа ышанмадылар, Кытайны халыкара хокук нормаларын бозуда гаепләделәр. Шар, чынлап та, ни өчендер бик оста рәвештә Американың стратегик атом-төш объектлары өстенә килеп чыккан иде. Американнар анда разведка җиһазлары бар дип шауладылар, әмма шарны бәреп төшерергә шикләнделәр. Белмәссең, анда әллә ниткән кораллар (мәсәлән, атом-төш коралы да) булырга мөмкин бит. Аэростатлар ярдәмендә тирәюньне арзанлы ысул белән фото-видеога төшереп алып була, сурәтләр галәмнән төшерелгәнгә караганда сыйфатлырак һәм төгәлрәк тә чыга. Монысы да сер түгел.

«Аэростатлар белән идарә итеп буламы?» – дигән сорауга да җавап уңай. Стратосферадагы агымнар турында гел яңартылып торучы метеомәгълүматларың булса, шарны теләгән юнәлештә хәрәкәтләндерә аласың. Зондны тиешле агымга күтәрергә, я төшерергә генә кирәк. Кытай армиясенең андый мөмкинлекләре бар. Берничә көн шикләнгәннән соң, американнар шарны бәреп төшерергә булдылар. Максат шарның шартлавын куркынычсыз итү һәм аның җиһазларын кулга төшерүдән гыйбарәт иде. Көньяк һәм Төньяк Каролина штатларының яр буендагы өч аэропорты һәм һава киңлекләре ябылды, күккә юк итүче F-22 һәм F-15 очкычлары, берничә Boeng КС-135 хәрби-транспорт самолеты күтәрелде һәм шар, шартлатылып, җиһазлары яр буендагы сайлыкка төште. Бу махсус шулай эшләнде, җиһазларны кулга төшерү дә максат ителгән иде. Кытай ярсулы протест белдерде һәм җавап бирәчәген игълан итте.

Шар гына түгел, Кытай – Америка мөнәсәбәтләре дә шартламадымы икән? АКШның дәүләт секретаре Блинкен Пекинга визит белән барасы иде, очрашу туктатылды.

Россиядә

РОССИЯ БЮДЖЕТЫНДА ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛ

Россия Финанс министрлыгы үткән атна ахырында салым керемнәре турында хисап бирде. Гыйнвар нәтиҗәләре шаккатарлык: казна керемнәре биш тапкыр кимегән. Бер ел элек гыйнварда 2 триллион сум салым җыелган булса, быел 400 миллиард кына. Федераль министрлык тынычландыра: вазгыять салым түләүдәге үзгәрешләргә бәйле «техник сәбәп»ләр аркасында гына шулай шомлы, ди. Күп кенә керемнәр вакытлыча исәпкә алып бетерелмәгән, бары шул гына.

2 февральгә керемнәр 414 миллиард сум тәшкил иткән, чыгымнар – 3,3 триллион. Үткән елның гыйнварында керемнәр – 2 триллион, чыгымнар 1,9 триллион сум булган. Үткән ел – профицит, быел гигант күләмдәге бюджет дефициты ягъни. Газета хәбәрчесе «чыгымнар» дигән өлешкә игътибар итүегезне сорый. Чыгымнар үткән елгыдан 1,74 тапкыр диярлек арткан. Керем өлеше, әйтик, нәрсәнедер исәпкә алып бетермәгәнгә генә шулай кискен кимегән дисәк тә, чыгымнар бик яхшы исәпләнгән бит инде. Гыйнварда исәпкә алып бетерелмәгән салымнарны китереп кушсаң да, керемнәр тәлинкәсе барыбер чыгым бизмәнен баса алмаячагы сукыр күзгә дә күренерлек. Димәк, бюджет дефицитлы һәм дефицит көтелгәннән күпкә зуррак булачак. Бер нәрсәне истә тотабыз: гыйнвар аенда казнага кергән нефть-газ керемнәре ике тапкыр диярлек кимегән. Сәбәбе аңлаешлы: бюджетны нефть «түшәме» баса һәм изә. «Кара алтын» чит илләргә бик зур күләмдә дисконт белән озатыла, транспорт чыгымнары да бик күпкә үсте. «Зур җиделек» куйган «түшәм»нән байтак арзанга сатабыз җир маен.

Февраль югалтулары тагын да зуррак булачак, чөнки нефть продуктларына берьюлы ике камчы суга: эмбарго һәм «түшәм» бәяләр. Бюджет керемнәрендә газ өлеше дә кискен кими. Газчылар түләгән файдалы казылмалар салымы 24 процентка чүккән, экспорт пошлинасы 50 процентка кимегән.

Казна капчыгын тутыру өчен, Финанс министрлыгы күпләп валюта сатарга ниятли. 7 февральдән валюта сатып 160,2 миллиард сум табыш алу планлаштырыла. Сәүдә (акчаны акчага алыштыру) 23 мартка кадәр барыр һәм көн саен 8,9 миллиард сумлык валюта сатылыр дип уйлыйлар. Бу сәүдәнең бер кызык ягы бар: күпләп сатканда, валюта курсы күтәрелә, сумныкы төшә һәм тиешле суммага җиткерү өчен валютаны күбрәк сатарга туры килә. Күбрәк сатсаң, курс тагын төшә һәм янә валюта өстәргә туры килә. Тагын бер нәрсә бар: валюта сатып кына бюджет тишеген томалап булмый барыбер.

Көнбатышта нефть продуктларына эмбарго кертелгәч, Россия 40 миллиард доллар керемнән колак кагар дип саныйлар. Өч триллион сумга якын өстәмә югалту дигән сүз бу. Икътисадчылар бюджетның чыгым өлеше дә планлаштырганнан бик күпкә югары булуын һәм акчаны оборона йотуын билгеләп үтәләр. Башка саннар китермибез, чөнки саннар барыбер начар якка үзгәрә.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

БЕРЕНЧЕСЕНӘ ӘЗЕР

Югары дәрәҗәдә булсын! Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов киләсе елда башкалада узачак «Киләчәк уеннары» халыкара турнирын оештыруга шундый бурыч куйды. Оештыру комитеты шул хакта фикер алышты.

Рөстәм Миңнеханов сүзләре белән әйткәндә, «Киләчәк уеннары» – цифрлы технологияләр һәм физик мөмкинлекләрне берләштерүче проект ул. Тәүге уеннарны Татарстанда үткәрүгә күрсәткән ышанычлары өчен, ул ил җитәкчелегенә рәхмәтен дә белдерде.

Искәртеп үтик: «Киләчәк уеннары» ярышы 2024 елның мартында Казанда узачак. 16 төрле юнәлештә ярышлар көтелә.

Татарстанны сайлаулары да юкка түгел. Оештыру комитеты утырышына видеоэлемтә аша кушылган Россия вице-премьеры Дмитрий Чернышенко сүзләренчә, республиканың халыкара дәрәҗәдәге ярышларны үткәрүдә тәҗрибәсе зур. Оештыру, әзерлек, инфраструктураны куллану җәһәтеннән дә Татарстан мактауга гына лаек. Дмитрий Чернышенко узган елның көзендә уеннар алдыннан узган сынау ярышларын да телгә алды. Вице-премьер сүзләренчә, аларга кызыксыну да зурдан, оештыру да көтелгәнчә – югары дәрәҗәдә булган.

Татарстан Рәисе әйтүенчә, хәзер республикада уеннарга әзерлек тулы куәткә алып барыла. Җитешсезлекләрне бетерү, тәкъдимнәрне исәпкә алу өчен вакыт бар. «Без уеннарга әзерлек буенча планлы эш алып барабыз. Республикада моның өчен кирәкле ресурслар җитәрлек», – диде Рөстәм Миңнеханов.

vk.com

2023 елның 5–11 февраль көннәрендә Казанда «Фиджитал уеннар»ның өченче этабы уза. Традицион спорт һәм киберспортны берләштергән ярышлар ике мәйданчыкта – IT паркта һәм «Казан Экспо»да үтә. Уеннар 5 төрле дисциплина буенча оештырыла.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Бергә кайгырабыз. Татарстан Рәисе, «Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеме Рәисе Рөстәм Миңнеханов Төркия Президенты Рәҗәп Таип Әрдоган һәм Сүрия Президенты Бәшәр Асадка кайгы уртаклашу телеграммалары юллады.

«Төркиядәге җимергеч җир тетрәү турындагы хәбәр Татарстанда яшәүчеләрдә бик авыр хисләр тудырды. Табигать афәтенең кеше корбаннарына һәм бик зур җимерелүләргә китерүенә бәйле кайгы уртаклашуны кабул итегез. Һәлак булганнарның туганнары һәм якыннарына теләктәшлек сүзләре, зыян күрүчеләрнең һәммәсенә тизрәк аякка басу теләген тапшыруыгызны сорыйм. Сезнең белән, тугандаш Төркия халкы белән югалту ачысын уртаклашабыз», – диелә Рәҗәп Таип Әрдоганга юлланган кайгы уртаклашу телеграммасында.

«Сүриянең төньяк районнарындагы җир тетрәү фаҗигасенә бәйле рәвештә кайгы уртаклашуны кабул итегез. Һәлак булганнарның туганнары һәм якыннарына теләктәшлек сүзләре, табигать афәтендә зыян күргәннәрнең барчасына тизрәк савыгу теләген тапшыруыгызны сорыйм. Сезнең белән, Сүрия халкы белән әлеге югалту ачысын бүлешәбез», – диелә Бәшәр Асадка юлланган кайгы уртаклашу телеграммасында.

ТАТАРСТАННЫҢ ДӘҮЛӘТ ГЕРБЫ КӨНЕ БЕЛӘН!

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе ФӘРИТ МӨХӘММӘТШИНның Татарстан Республикасы Дәүләт гербы көне уңаеннан КОТЛАВЫ

Хөрмәтле татарстанлылар! Сезне ихлас күңелдән Татарстан Республикасы Дәүләт гербы көне – төрле милләттә һәм диндә булган кешеләрне Татарстанның күпгасырлык тарихын ихтирам итүдә, республиканың бүгенге казанышларын саклауга һәм арттыруга уртак омтылышта берләштерә торган бәйрәм белән котлыйм.

Дөньяда элек-электән илләр һәм аларның төбәкләре үзенчәлекләрен чагылдыра, гражданнарны тәрбияләүдә әһәмиятле роль уйный торган өч рәсми символ – Дәүләт флагы, Дәүләт гербы һәм Дәүләт гимны – яшәп килә. Иҗтимагый-сәяси тормышта бу атрибутларның әһәмияте бәһасез, чөнки граждан булып формалашу, Ватанның бүгенгесе һәм киләчәге өчен җаваплы булу нәкъ менә аларга хөрмәт белән караудан башлана. Шуңа күрә дә дәүләт символлары закон дәрәҗәсендә ышанычлы яклана, массакүләм ватанпәрвәрлек, спорт, белем бирү чараларында киң кулланыла.

Татарстанның бүгенге символлары вакыт сынавын узды, җәмгыять тормышының аерылгысыз өлешенә, милләт һәм дәүләт бердәйлегенең мөһим факторына әйләнде. Татарстан Республикасы Гербы моннан утыз бер ел элек, 1992 елның 7 февралендә расланды һәм Флаг, Гимн кебек үк республикабыз халкын берләштерә. Идел буе болгарларының борынгы геральдика символларын нигез итеп алган филолог Н.Ханзафаров, монументалист рәссам Р.Фәхретдинов – бүген Татарстаннан читтә дә билгеле булган гербны иҗат иткән авторлар. Алар бу эшне күпмилләтле Татарстанның төп символын булдыруга үз өлешен керткән фикердәшләре белән бергә башкарган. Кояш түгәрәге җирлегендә урнашкан, янтавында калканы булган канатлы горур барс халкыбызның тормышын саклый һәм уңыш, игелекле гамәлләр, уңдырышлылык һәм алгарышны гәүдәләндерә. Гербның төсләре шулай ук тирән мәгънәгә ия: алтын – нәфислек, матурлык, җир асты байлыклары төсе; яшел – яңарыш, торгызу; ак – ниятләр сафлыгы; кызыл – җитлегү, көч-куәт һәм яшәү ныклыгы төсе.

Ышанам ки, Республика Гербы татарстанлылар өчен алга таба да Ватанга карата горурлык һәм мәхәббәт хисе уята, югары хезмәт, фәнни һәм спорт казанышларына илһамландыра, ата-бабаларыбызның традицион рухи-әхлакый кыйммәтләренә тугры булып калуны чагылдыра торган изге символ булачак. Бүген безнең бөек илебез кичергән авыр чорда бу бигрәк тә мөһим. Шушы истәлекле көндә сезгә тынычлык, игелек, бәхет һәм иминлек телим!

КОТЛЫЙБЫЗ!

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлеге башлыгы **Вафина** Рәмзия Рамазан кызы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Яңа Кәшер авыл җирлеге башлыгы **Гыйниятуллина** Лилия Марс кызы, «Түбән Кама шәһәренең мәгълүмат үзәге» муниципаль автоном учреждениесе административ бүлеге баш белгече (эш башкару белгече) **Идрисова** Флүсә Рәүф кызы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының оештыру бүлеге башлыгы **Рәхимова** Раушания Мансур кызы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чубар Абдул авыл җирлеге башлыгы **Фәтхетдинов** Нияз Әдгать улы, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттырудагы казанышлары, Лениногорск муниципаль районының финанс-икътисадый үсешенә өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе рәисе **Хәбибуллина** Фирдәүс Фәрит кызы **«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

«Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппараты» муниципаль казна учреждениесенең эш башкару идарәсе башлыгы урынбасары – гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге башлыгы **Васильева** Диларә Фәрит кызына, «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының республика ресурс үзәге» дәүләт казна учреждениесе директоры **Горшунова** Марина Валентиновнага, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль регистр формалаштыру бүлеге әйдәүче киңәшчесе **Парамонова** Эльмира Мәхмүт кызына, «Ярдәм-Помощь» илкүләм хәйрия фонды вице-президенты **Гыйльметдинова** Мәликә Рәфкать кызына **«Татарстан Республикасының атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Авыл хуҗалыгы

БЫЕЛГА ҮЗГӘРЕШСЕЗ

СУБСИДИЯ КЕМНӘРГӘ КАРАЛГАН?

Быел республика бюджетыннан шәхси хуҗалыкларга каралган субсидия 110 млн сумга күбрәк биреләчәк. Бу хакта Татарстанның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетында хәбәр иткән иде. Аның сүзләре буенча, узган ел бу максатлар өчен 426 млн сум бирелсә, быел 536 млн сум акча каралган.



Илдар Мөхәммәтҗанов

Билгеле булганча, шәхси хуҗалыкларга субсидияләр сыер, кәҗә һәм өч яшьтән зуррак булган бия, токымлы бозаулар сатып алыр өчен бирелә. Моннан тыш, быел мини-ферма төзер өчен дә субсидия күләме 80 млн сумнан 100 млн сумга кадәр арттырыла. Узган ел кош-корт тотучылар игътибардан читтә калган иде. Быел аларга да ярдәм кабаттан торгызылачак. Әлеге максатлар өчен республика казнасыннан 70 млн сум өлеш чыгармакчылар.

Тик әлеге утырыш вакытында Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты рәисе урынбасары Таһир Һадиев шәхси хуҗалыклар субсидияне бары тик үзмәшгуль буларак теркәлгән очракта гына аласын әйткән иде. «Белүебезчә, бүген алар арасында үзмәшгуль булып теркәлүчеләр юк. Димәк, алар дәүләт ярдәменнән мәхрүм калачак», – диде ул.

Без әлеге хәбәргә ачыклык кертергә теләп, республиканың Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына мөрәҗәгать иттек.

– Республика ярдәмен барлык шәхси хуҗалыклар да алачак. Узган ел ул 44 мең хуҗалыкка бирелде. Бу мәсьәләдә бернинди дә яңалык юк. Монда сүз башка хакта барган булырга тиеш, – дип аңлатты министрлык вәкиле. – Әйе, чыннан да, министр кушуы буенча, федераль бюджеттан бирелә торган субсидияне үзмәшгуль шәхси хуҗалыкларга бирү мәсьәләсе өйрәнелә. Тик бу, беренчедән, бәрәңге һәм яшелчәләр үстерү белән шөгыльләнүче хуҗалыкларга гына кагыла. Һәм, икенчедән, әлегә бу турыда төгәл мәгълүмат юк. Ул гамәлгә ашырылган очракта да, бары тик киләсе елдан гына эшли башлаячак.

Шул ук вакытта, Марат Җәббаров сүзләренчә, быел фермерларга бирелә торган ярдәм күләме кыскартылган. Шулай итеп, федераль ярдәмне фермерлар 359 млн сумга азрак алачаклар – 576 млн сум.

– Субсидия күләме кыскартылу исәпләүнең яңа методикасына бәйле, – дип аңлатты министр. – Элек грант алучының планлаштырылган эш урыннары исәпкә алынса, хәзер фермер хуҗалыгының чынлыкта җитештергән продукциясе төп күрсәткеч булып торачак. Шул ук вакытта чыгымнар өчен субсидияләрнең лимитлары 142 млн сумга кадәр арттырылды.

Сүз уңаеннан, шушы көннәрдә авыл хуҗалыгы министры урынбасары Ленар Гарипов республика умартачылары белән киңәшмә уздырды. Анда төп игътибарны токымлы умартачылыкны үстерүгә бирделәр. Татарстан Россиядә умартачылыкны үстерү буенча лидерларның берсе булып тора. Узган ел бездә 9 мең тоннадан артык бал җитештерелгән. Татар умартасы (татар популяциясе белән урта рус токымлы умарта) аерым игътибарга лаек. Кызганычка, әлеге токымның юкка чыгу куркынычы бар. Белгечләр сүзләренчә, моның сәбәбе – тиешле контроль булмау һәм селекция эшенең өзлексез алып барылмавы. Шунлыктан быелдан нәсел хуҗалыкларына ярдәм күрсәтә башлаячаклар. Аларга татар популяциясе белән умарта пакетларын сатуга киткән чыгымнарның бер өлешен компенсацияләүгә субсидияләр биреләчәк.

Зөһрә САДЫЙКОВА

БАЛГА ЯБЫШКАН БӨҖӘК КЕБЕК

«ЭШ» 1918–1920 «ТАТАРСТАН ХӘБӘРЛӘРЕ» 1920–1922 «ТАТАРСТАН» 1922–1924 «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» 1924–1951

«ВТ» – 105 12 март 2023

1951–1960 «СОВЕТ ТАТАРСТАНЫ» 1960–1992 «СОЦИАЛИСТИК ТАТАРСТАН» 1992– «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»

Язу-сызу эшенә бирелгән кырык елдан артык гомер. Күпме бу, азмы? Шул вакыт эчендә, кимендә, дүрт дәвер кичергәнебезне истә тотканда, бик озак еллар булырга тиеш инде ул: совет заманы, аннан – үзгәртеп кору, бераздан капитализмга керү чорлары һәм, ниһаять, икътисадый мөстәкыйльлеккә ирештек, дип канат ярган чак. Каршы төшеп маташучылар булса да, танырга кирәк, журналистика аларның һәрберсендә хакимиятнең идеологик коралы булды. Хикмәт шунда: кайсыдыр бер чорда цензура ачыктан-ачык эшләде, икенчеләрендә эчке цензура дигәнебез тышкысыннан да уздырып җибәрде.

Бу дәверләр аралыгындагы тагын бер үзенчәлекне әйтмичә кала алмыйм. Аларның беренче икесендә матбугат һәм анда эшләүчеләр, аларның сүзе күпмедер дәрәҗәдә хөрмәткә ия иде. Хезмәтләренең хакы да уртача күрсәткечләрдән югарырак булды. Әлеге дәверләрнең соңгыларында инде журналист һөнәрен хезмәт күрсәтү өлкәсенә төшерделәр. Шуның белән бергә каләм кыйммәте плинтустан түбәнрәк йөри башлады.

Замандашлар белән очрашканда без моның турында ачынып-ачынып сөйләшәбез. Яшьләр сүзгә катнашса: «Сез яшьлегегезне сагынасыз», – дип көләргә дә мөмкиннәр. Анысы да хак. Ләкин безнең үз дәлилләребез: я, әйтегез әле, кайсыгыз бүген вазыйфасы ул чактагы беренче секретарьга тиң район башлыгының «ишегенә тибеп» керә ала? Кайсыгыз районда яшәүче сугыш ветераннарының хәлен тәнкыйтьләп, партия аппаратындагы чиновникларны эштән читләштерүгә ирешә ала? Кайсыгызны, халыкның фикерен белешеп, чынбарлыкны республикага чәчмәсә ярар иде дип, тәнкыйть хаты буенча килгән өчен районнан чыгып киткәнче сагалап йөргәннәре бар? Мәрхүм Мидхәт ага Хөснимәрдановны искә төшерәм. Чормада яшәүче ятим карчыкның кайгы-хәсрәте турында газетада ике тапкыр язып чыкты ул. Шулай тавыш куптарып, аңа фатир бирдерүгә ирешкән иде мәшһүр татар журналисты. Үзем хосусыйлаштыру башланганнан соң, уңышлы эшләүче предприятиене коллектив кулыннан тартып алырга маташулары турында ике газетада өч тапкыр язма биргән идем. Нәтиҗәсе генә булмады. «Башка заман – башка гадәтләр» килеп кергән чорга туры килде шул алар.

Чорыбызның намусы булырлык шәхес – драматург Туфан абый Миңнуллинга ул депутат булган чакта шундыйрак сорау биргәннәр иде: «Сез сессияләрдә хакимият сәясәтен күп тәнкыйтьлисез. Алай да түрәләр арасында иң хөрмәтле кешеләрнең берсе булып йөрисез? Моңа ничек ирешәсез?» Язучы бу сорауга: «Мин аерым кешене тәнкыйтьләмим, түбәнсетмим, мыскыл итмим. Мин проблеманы күтәрәм, шуны хәл итмәүне тәнкыйтьлим», – дип җавап бирде. Акыл иясенең бу сүзләре, журналистиканы кәсеп кенә түгел, һөнәр итеп сайлаганнарга да туры килә.

Журналистиканың күп кенә профессияләрдән өстен ягы шунда: ул аңа тормышның төрле өлкәләренә үтеп керергә мөмкинлек бирә. Чорының шөһрәтле шәхесләре, кызыклы кешеләр белән таныштыра. Бу яктан үземне бәхетле дип саныйм. Тәнкыйть, проблема артыннан гына йөрелмәде, билгеле. Университет, КХТИ, педагогия институты, башка вузларның галимнәрен, ректорларын, проректорларын, министрларны, «кызыл директор»ларны сәгатьләр буе сөйләштереп утыру өчен үзеңнең дә әзерлегең кирәк. Кемнәр генә юк иде алар арасында – Миркасыйм Усманов, Петр Кирпичников, Шәүкәт Хәбибуллин, Әхмәт Галиев, Ренат Галиев, Ренат Мөслимов, Яхъя Абдуллин… Журналистика ул шәхесләрнең генә түгел, үз фикереңне һәм карашларыңны укучыларга, халыкка җиткерү юлларын ача. Югары хакимият вәкилләре дә андый журналистларның иҗатын күзәтеп бара, аларның фикеренә колак сала. Һәрхәлдә, без сагынган чорда шулай иде.

Уңайсызланмыйча әйтергә була: безнең хезмәтне күрделәр. Шулар арасында берничәсен аерып күрсәтер идем. 1979 елда Казан дәүләт университеты үзенең 175 еллыгын билгеләп үтте. Мәктәп һәм фән бүлегенә күптән түгел генә күчерелгән Илсөяр газетада университетның мактаулы гыйльми мәктәпләре, анда эшләүче галимнәргә багышланган цикл бастырып чыгарды. Ул елны КФУны Ленин ордены белән бүләкләделәр, ә миңа КФУ турында альбом һәм Почет грамотасы бирелде. Аны тапшырганда ректор Александр Коновалов, кулымны кысып: «Ул башка газеталар эшләмәгән эшне башкарып чыкты», – диде, «Социалистик Татарстан»ны рус телендә чыгучы матбугаттан өстен куеп.

Ул заманнарда мактаулы исемнәр, бүләкләрне үзең юллап, дуслар аша әйттереп алу, пачкалап бирү юк иде бит. Әле менә архивларны актарып утырам. 1987 елгы газетада Матбугат көне уңаеннан журналистлар Илсөяр Хәйруллина һәм Александр Бусыгинны Республика журналистларының Хөсәен Ямашев исемендәге премиясе белән бүләкләү турында Хөкүмәт карары басылган.

«ВТ» архивыннан

«Социалистик Татарстан»ның 1986 ел истәлеге.

Аны безгә Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт театры бинасында Журналистлар берлеге рәисе Илгиз Кәлимуллин тапшырган иде. Аннан соң «Бәллүр каләм» белән бүләкләү, Татарстанның һәм Россиянең атказанган журналисты исемнәрен дә бирү булды. Шулай да иң истә калганы шул беренчесе иде кебек. Хәер, 2004 елда Россиянең атказанган журналисты исеме бирелү турындагы таныклыкны кулыма тоттырганда, Беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиевнең: «Илсөяр ул безне мактап кына тормый, еш кына хакимиятне тәнкыйтьләп тә ала», – дигән бәясе дә онытылмый икән әле.

«Социалистик Татарстан» чагында да, «Ватаным Татарстан»га әйләнгәч тә татарның иң зур тарихлы, абруйлы газетасында эшләү – журналистлар өчен дә, башка хезмәткәрләр өчен дә зур дәрәҗә. Мин әйтәм, бирегә бер кергән һәм үз эшенә чын күңелен салган кеше, балга ябышкан бөҗәк кебек, аннан кубып китә алмый.

Илсөяр ХӘЙРУЛЛИНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 26 гыйнварында кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 5 өлешенең 3 пунктына (2021 елның 5 маендагы 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2021, № 36 (I өлеш), «чит ил агенты функцияләрен башкара торган коммерциягә карамаган оешмалар» сүзләрен «чит ил агентлары» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2 статья

«Татарстан Республикасы референдумы турында» 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 44 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8; 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 пунктның «о» пунктчасында «чит ил агенты функциясен үтәүче коммерциягә карамаган оешмалар, чит ил агенты функцияләрен башкаручы чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары реестрына мәгълүмат кертелгән Россия юридик затлары» сүзләрен «чит ил агентлары булып торучы юридик һәм физик затлар һәм чит ил агентлары тарафыннан гамәлгә куелган Россия юридик затлары» сүзләренә алмаштырырга;

2) 6 пунктның икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

3 статья

«Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 46 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (II өлеш); 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 5 (II өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8, № 12; 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 пунктның «о» пунктчасында «чит ил агенты функциясен үтәүче коммерциягә карамаган оешмалар, чит ил агенты функцияләрен башкаручы чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары реестрына мәгълүмат кертелгән Россия юридик затлары» сүзләрен «чит ил агентлары булып торучы юридик һәм физик затлар һәм чит ил агентлары тарафыннан гамәлгә куелган Россия юридик затлары» сүзләренә алмаштырырга;

2) 6 пунктның икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

4 статья

Татарстан Республикасы Сайлау кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяның 11 өлешендәге икенче җөмләне төшереп калдырырга;

2) 18 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 13 пункт өстәргә:

«13) чит ил агентлары реестрына кертелгән затлар.»;

б) 6 өлешнең 2 пунктында «1, 2 һәм 12» сүзләрен «1, 2, 12 һәм 13» сүзләренә алмаштырырга;

в) 8 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 7 пункт өстәргә:

«7) комиссия әгъзасы чит ил агентлары реестрына кертелгәндә.»;

3) 20 статьяның 2 өлешендә «1 – 6, 12 пунктларында» сүзләрен «1 – 6, 12 һәм 13 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

4) 39 статьяның 1 өлешендәге 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) әгәр кандидат чит ил агенты яисә чит ил агенты белән аффилиацияләнгән кандидат булса, – бу хакта белешмәләр.»;

5) 44 статьяның 7 өлешендәге икенче абзацта «чит ил агенты функциясен башкаручы физик зат» сүзләрен «чит ил агенты» сүзләренә алмаштырырга, «чит ил агенты функциясен башкаручы зат» сүзләрен «чит ил агенты» сүзләренә алмаштырырга, «чит ил агенты функциясен башкаручы кандидат (кандидатлар)» сүзләрен «чит ил агенты (чит ил агентлары) булып торучы кандидат (кандидатлар)» сүзләренә алмаштырырга;

6) 46 статьяда:

а) 4^8 өлештә «чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат» сүзләрен «чит ил агенты» сүзләренә алмаштырырга, «чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат» сүзләрен «чит ил агенты» сүзләренә алмаштырырга;

б) 5 өлештә «чит ил агенты функциясен башкаручы физик зат» сүзләрен «чит ил агенты» сүзләренә алмаштырырга, «чит ил агенты функциясен башкаручы зат» сүзләрен «чит ил агенты» сүзләренә алмаштырырга;

7) 55 статьяның 5^1 өлешендә «чит ил агенты функциясен башкаручы физик зат булып торучы» сүзләрен «чит ил агенты булып торучы» сүзләренә алмаштырырга, «чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат» сүзләрен «чит ил агенты» сүзләренә алмаштырырга, «чит ил агенты функциясен башкаручы физик зат» сүзләрен «чит ил агенты» сүзләренә алмаштырырга, «чит ил агенты функциясен башкаручы кандидат белән аффилиацияләнгән кандидат» сүзләрен «чит ил агенты белән аффилиацияләнгән кандидат» сүзләренә алмаштырырга;

8) 58 статьяда:

а) 10^3 өлештә «Чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат булып торган» сүзләрен «Чит ил агенты булып торучы» сүзләренә алмаштырырга, «чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат» сүзләрен «чит ил агенты» сүзләренә алмаштырырга, «чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат» сүзләрен «чит ил агенты» сүзләренә алмаштырырга, «чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидат булып торган» сүзләрен «чит ил агенты белән аффилиацияләнгән кандидат булып торучы» сүзләренә алмаштырырга;

б) 10^4 өлештә «чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик затлар исемлегенә кертелгән физик затның яисә чит ил агенты функцияләрен башкаручы чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары реестрына үзе турында мәгълүмат кертелгән физик затның» сүзләрен «чит ил агенты булып торучы физик затның» сүзләренә алмаштырырга, «чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик затлар исемлегенә кертелгән кайсы физик затның яисә чит ил агенты функцияләрен башкаручы чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары реестрына үзе турында мәгълүмат кертелгән кайсы физик затның» сүзләрен «чит ил агенты булып торучы кайсы физик затның» сүзләренә алмаштырырга;

9) 61 статьяда:

а) 4^1 өлештә «чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат булып торучы» сүзләрен «чит ил агенты булып торучы» сүзләренә алмаштырырга, «чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат» сүзләрен «чит ил агенты» сүзләренә алмаштырырга, «чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат» сүзләрен «чит ил агенты» сүзләренә алмаштырырга, «чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидатны» сүзләрен «чит ил агенты белән аффилиацияләнгән кандидат булып торучы кандидатны» сүзләренә алмаштырырга;

б) 9^1 өлештә «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлаулар әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы комиссия» сүзләренә алмаштырырга;

10) 62 статьяның 12 өлешендә «Чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат булып торучы» сүзләрен «Чит ил агенты булып торучы» сүзләренә алмаштырырга, «чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат» сүзләрен «чит ил агенты» сүзләренә алмаштырырга, «чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат булуы» сүзләрен «чит ил агенты булуы» сүзләренә алмаштырырга;

11) 64 статьяның 3 өлешендә «Чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат» сүзләрен «Чит ил агенты» сүзләренә алмаштырырга, «чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат» сүзләрен «чит ил агенты» сүзләренә алмаштырырга;

12) 67 статьяның 14 өлешендәге 14 пунктында «чит ил агенты функциясен үтәүче коммерциягә карамаган оешмалар, чит ил агенты функцияләрен башкаручы чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары реестрына мәгълүмат кертелгән Россия юридик затлары» сүзләрен «чит ил агентлары булып торучы юридик һәм физик затлар һәм чит ил агентлары тарафыннан гамәлгә куелган Россия юридик затлары» сүзләренә алмаштырырга;

13) 68 статьяның 1 өлешендәге икенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

14) 73 статьяның 4 өлешендә «чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат» сүзләрен «чит ил агенты» сүзләренә алмаштырырга, «чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат» сүзләрен «чит ил агенты» сүзләренә алмаштырырга;

15) 75 статьяның 10^1 өлешендә «чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат» сүзләрен «чит ил агенты» сүзләренә алмаштырырга, «чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат» сүзләрен «чит ил агенты» сүзләренә алмаштырырга;

16) 105 статьяның 2 өлешендә «муниципаль берәмлекнең тиешле сайлау комиссиясе» сүзләрен «тиешле территориаль комиссия» сүзләренә алмаштырырга;

17) 1 нче кушымтага искәрмәдә «чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат» сүзләрен «чит ил агенты» сүзләренә алмаштырырга, «чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат» сүзләрен «чит ил агенты» сүзләренә алмаштырырга.

5 статья

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 24 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 11 пункт өстәргә:

«11) аның тарафыннан чит ил агенты статусы алынса.»;

2) 23 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5) муниципаль хезмәткәрнең чит ил агенты статусын алуы.».

6 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2023 ел, 03 февраль, № 2-ТРЗ

Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 45 статьясына һәм «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 26 гыйнварында кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 45 статьясындагы 2^1 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 60 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2^1. Бала, шул исәптән уллыкка (кызлыкка) алынган яисә гаиләдә опекада яисә попечительлектә булган, тәрбиягә алган гаиләне дә кертеп, абыйсы һәм (яисә) апасы (бертуган һәм атасы йә анасы башка булган, уллыкка (кызлыкка) алынган), опекуннары (попечительләре) бу баланың ата-анасы (законлы вәкилләре) булган балалар яисә ата-анасы (законлы вәкилләре) бу баланың опекуннары (попечительләре) булган балалар укый торган дәүләт яисә муниципаль мәгариф оешмаларына төп гомуми белем бирү программалары буенча белем алуга өстенлекле кабул ителү хокукына ия була, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 67 статьясындагы 5 һәм 6 өлешләрендә каралган очраклар моңа керми.».

2 статья

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 14 статьясындагы 2^1 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2^1. Бала, шул исәптән уллыкка (кызлыкка) алынган яисә гаиләдә опекада яисә попечительлектә булган, тәрбиягә алган гаиләне дә кертеп, абыйсы һәм (яисә) апасы (бертуган һәм атасы йә анасы башка булган, уллыкка (кызлыкка) алынган), опекуннары (попечительләре) бу баланың ата-анасы (законлы вәкилләре) булган балалар яисә ата-анасы (законлы вәкилләре) бу баланың опекуннары (попечительләре) булган балалар укый торган дәүләт яисә муниципаль мәгариф оешмаларына төп гомуми белем бирү программалары буенча белем алуга өстенлекле кабул ителү хокукына ия була, Федераль законның 67 статьясындагы 5 һәм 6 өлешләрендә каралган очраклар моңа керми.».

3 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2023 ел, 03 февраль, № 3-ТРЗ

Татарстан Республикасы Җир кодексының 2 һәм 45 статьяларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 26 гыйнварында кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 3 пунктчасында «Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары» сүзләрен «Татарстан Республикасының башка законнары» сүзләренә алмаштырырга;

2) 45 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 7 пунктча өстәргә:

«7) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән булган җир кишәрлегенә өлешле гомуми милек хокукында өлешләрнең гектарларда яисә балло-гектарларда белдерелгән күләмнәрен гади ялгыз вакланма рәвешендә билгеләү нәтиҗәләрен раслау турында карар.».

2 статья

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясындагы 2 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пункты 2023 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2023 ел, 03 февраль, № 4-ТРЗ

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 26 гыйнварында кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 14 өлештә «15 эш көне» сүзләрен «10 эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

2) 16 өлештә «10 эш көне» сүзләрен «җиде эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

3) 17 өлештә «10 эш көне» сүзләрен «җиде эш көне» сүзләренә алмаштырырга.

2 статья

Әлеге Закон 2023 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2023 ел, 03 февраль, № 5-ТРЗ

«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 26 гыйнварында кабул ителде

1 статья

«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» 2006 елның 20 июнендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2012, № 3, № 7 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 2 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 1 өлешендәге алтынчы абзацына «укыту,» сүзеннән соң «халыкны санитария-гигиена ягыннан агарту һәм» сүзләрен өстәргә;

2) 5 статьяда:

а) 1 өлештә «һәм укыту» сүзләреннән соң «, халыкны санитария-гигиена ягыннан агарту һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:

«5. Җәмгыятьтә санитария-гигиена культурасын һәм гражданнарда сәламәт яшәү рәвешенә мотивация булдыру максатларында халыкны санитария-гигиена ягыннан агарту үткәрелә, ул, дөрес туклануны һәм зарарлы гадәтләрдән баш тартуны да кертеп, сәламәт яшәү рәвешен булдыру, авыруларны профилактикалау, сәламәтлекне саклау һәм ныгыту өчен кирәкле белемнәрне, халыкның санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итүнең башка мәсьәләләре буенча белемнәрне тарату юлы белән, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларыннан, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, басма продукцияләрдән (белешмәләрдән, буклетлардан, плакатлардан һәм башкалардан), социаль рекламадан файдаланып, шулай ук оештырылган коллективларда чаралар, гражданнарга индивидуаль консультацияләр үткәргәндә гамәлгә ашырыла.

Халыкны санитария-гигиена ягыннан агартуны үткәрү тәртибе, шартлары һәм рәвешләре һәм аны тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибе мәгариф турындагы законнар нигезендә билгеләнә.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2023 ел, 03 февраль, № 6-ТРЗ

Белдерү

Кадастровым инженером Кутдусовой Натальей Генадьевной (СНИЛС № 128-830-216 57), являющейся членом СРО АКИ «Поволжье» (номер в реестре СРО «0182», дата вступления 05.07.2013 г.), квалификационный аттестат № 16-11-417, адрес: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1, адрес электронной почты: m2405085@yandex.ru, тел.: 8(843)2405085), в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:50:300425:6, расположенного по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, отс Кировский, ул. Пороховая, д. 7, выполняются кадастровые работы по уточнению границ и площади земельного участка.

Заказчиком кадастровых работ является Туганова Г.Н. (тел.: +79656107949). Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования границ состоится по адресу: 420129, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1 10 марта 2023 г. в 10.30 ч. С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: 420129, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1. Обоснованные возражения относительно местоположения границ, содержащихся в проекте межевого плана и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются ежедневно с 9.00 до 17.00 часов с 20 февраля 2023 г. до 10 марта 2023 г. по адресу: 420129, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1.

Смежные земельные участки с правообладателями, которых требуется согласовать местоположение границ:

– 16:50:300425:2, расположен по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Кировский район, ул. Пороховая, уч. 9;

– 16:50:300425:5, расположен по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, отс Кировский, ул. Пороховая, д. 5.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы, подтверждающие права на соответствующий земельный участок.

80 ЯШЬКӘ КАДӘР ТАБИБ БУЛЫП ЭШЛӘГӘН ӘХТӘМ ШӘЙХЕЛМӘРДАНОВ:

«Ашыгыч ярдәм цирк түгел»

«Биемичә түзеп кара. Сездә дә мәдәният йортына биеп керәләрме? Татарстанның атказанган табибы – 80 яшькә җиткән Әхтәм абый менә шулай бии-бии керә». Актаныш районы Иске Сәфәр авылы мәдәният йортының «ВКонтакте» челтәрендә менә шундый видеоязманы күргәч, биючене тизрәк эзләп табарга булдык. Кем икән бу табаннары ут чәчеп торган, яшь йөрәкле биюче абзый?

Әхтәм абый Шәйхелмәрданов 79 яшькә кадәр ашыгыч ярдәм табибы булып эшләгән икән. Пенсиягә чыкканнан соң 19 ел! Соңгы вакытта Чаллыдан Түбән Камага барып, сырхауларга ярдәм кулы сузган. Әле китәргә исәбе булмаган, тик яше өлкәнәю генә уңайсызландырган. «Минем кебек 1943 елгы сугыш чоры балалары хәзер ашыгыч ярдәмдә юк бит инде», – ди ул, елмаеп. Ярты ел элек эшеннән китсә дә, табиб булудан туктамаган. Хәзер гаиләсенең, якыннарының сәламәтлеген кайгырта. Шул ук вакытта «энә кадау» белән дә шөгыльләнә. Невропатолог янына киңәш сорап килүчеләр дә бар.

Казан дәүләт медицина институтының дәвалау эше факультетын тәмамлый ул. Аннан соң өстенә солдат шинеле кия. Юллама буенча Актанышка кайтырга тиеш булса да, бишенче курста үзе практика үткән Әлмәт хастаханәсен сайлый. Хезмәт юлын невропатолог буларак башлый. Пермь краеның Березники шәһәренә дә китәргә туры килә. Читтән кайткач, Әлмәт, Чаллы хастаханәләрендә – невропатолог, шул ук вакытта ашыгыч ярдәм табибы.

– Әхтәм абый, ашыгыч ярдәм табибы өчен иң авыры нәрсә булды? – дип сорадым аннан.

– Түбән Камада йөрәк буенча реанимация бригадасында эшләгәндә, иң авыр чакыруларга бардым. Кемдер аңын югалткан, агуланган, кемдер үз-үзенә кул салган. Арада сәрхушләре дә бар. Барысы да – кеше бит. Урамда калдырып булмый. Менә шунда бер хәлгә шакката идем. Хәзер интернет заманы, барысының да кулында – телефон. Берәү аңсыз ята. Шул ук вакытта икенче берәү, табибның һәрбер хәрәкәтен камерага төшереп, гайрәтне чигерә. Кеше үлем белән көрәшкәндә кирәкме бу? Һәр минут кадерле бит. Адәм баласы артыгын кылана башлады. Авыруны ашыгыч ярдәм машинасына салырга булышучылар бик аз күренә. Аларга цирктагы кебек карап торырга кирәк. Ярдәм итүеңне түгел, тизрәк кимчелегеңне күрергә тырыша, – ди 43 ел ашыгыч ярдәм табибы булып эшләгән Әхтәм Шәйхелмәрданов.

Аннан Гиппократ антына тугрылык турында да сораштык. Әхтәм абый әйтүенчә, күңелеңдә вөгъдә булмаса, ант бирүдән генә берни дә үзгәрмәячәк. «Безне укыганда, син дошманыңа да ярдәм кулы сузарга тиеш, дип өйрәттеләр. Мин – әтисез үскән крестьян малае. Хезмәтемне гадел үтәргә тырыштым. Кешенең хәлен аңламасаң, авыруларның диагнозын җыеп кына булмый. Тиешле ярдәм күрсәтә белергә кирәк. Кызганыч, табиблар арасында «намус» дигән нәрсә юкка чыгып бара», – ди ул.

Син басмасаң, мин басам...

Әхтәм абый җаен Иске Сәфәр клубына авыл тарихына багышланган китапны тәкъдим итү кичәсенә кайткан икән. Менә шунда аның тыпырдап биегәнен видеога төшергәннәр дә инде.

– Гармун уйнап карадым, тик булып чыкмады. Егет кешегә 70 төрле һөнәр дә аз дип, бию белән шөгыльләндем. Медицина институтында укыганда, мех комбинатының бию түгәрәгенә йөргән идем. Көй яңгыраганда, биемичә түзә алмыйм, – ди.

Әхтәм абыйның авылда нигезе дә, туганнары юк. Шулай да туган җирен бөтенләй онытып бетерми, гаиләсе белән Сабан туена кайталар. Ул туган бер урамлы Абдуллин авылы юкка чыккан инде. Исеме дә башка. Дөресрәге, янәшәдәге Иске Сәфәр авылына кушылган.

Табибның үзенең сәламәтлеге ничек икән? Ул көн саен иртән салкын су белән коена. Кышын чаңгыда йөри. Өендә физик күнегүләр ясый. Анализлар биреп, сәламәтлеген тикшертеп, үзгәрешләрне күзәтеп, чарасын күреп тора. «Холестерин күп булса, кан юлларына юшкын утырып, атеросклерозга китерергә мөмкин. Шуңа күрә холестеринны гел киметеп торырга кирәк. Майның да, шикәрнең дә, аксымның да кирәге бар. Аларны чикләп кенә яшәп булмый. 40тан узганнарга иртән бер стакан җылымса су эчәргә кирәк. Иртүк бер кашык җитен мае эчеп кую да файдалы», – ди ул.

Сәрия МИФТАХОВА

Газетабыз турниры

БАТЫРЛЫК КИРӘК ЧАКТА

Көрәш җәмәгатьчелеге зур бәйрәмгә әзерләнә. Герой-шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә «Ватаным Татарстан» газетасы гамәлгә куйган көрәш турнирының 60нчысы 17–18 февральдә Казанда уза. Юбилей бәйгесенең батырлары да күбрәк булачак. Быелгы ярышта җиңүчеләр башка еллардагы кебек 10 түгел, ә 11 авырлык категориясендә ачыклана.

Җиңүчеләр арта

1964 елда узган тәүге ярышта батырлар 4 категориядә генә бил алышкан. Җиңүче булып Зөфәр Ханов (Сарман), Габдулла Ямалов (Сарман), Талип Яруллин (Әлки), Габдулла Хафизов (Чаллы) таныла. 1964 елның көзендә Казанның «Динамо» җәмгыяте спорт залында үткәрелгән ярышта 11 командадан иллеләп көрәшче катнашкан. Икенче елны исә командалар саны –24кә, ә катнашучылар саны 91гә җиткән. 1966 елда исә 30 районнан 121 пәһлеван җыелган, шулай итеп аларның саны гел артып барган. Моңа, әлбәттә, бәйгедә авырлык категорияләре арту да сәбәпче булгандыр. Соңгы елларда турнирда батырлар 10 категориядә ачыкланды. Быел исә алар 11 булачак. Авырлыгы 115 килодан артмаган егетләр аерым категориядә бил алышачак. 60 нчы турнирның төп яңалыкларыннан берсе бу. Татарстан Көрәш федерациясенең башкарма директоры Марсель Таһиров әлеге үзгәрешне авырлыгы зур булган көрәшчеләр саны күп булу белән аңлатты. Кечерәк категорияләрдә авырлык аермасы 5–10 кило гына булса, 100не узгач кинәт кенә 130га күтәрелә. Кыскасы, әнә шул аерманы киметеп, ярышны тагын да гаделрәк итү теләге бар.

Узган ел март аенда узган 59 нчы бәйгедә 47 команда һәм 370 көрәшче катнашты. Үз ишләре арасында җиңүче булып Илсур Гыймадетдинов (Кукмара), Илнар Закиров (Чистай), Айназ Тимеров (Чаллы), Динар Кәримуллин (Лаеш), Рамил Синәкәев (Әлмәт), Ренас Кәлимуллин, Раил Сәлахетдинов (Кукмара), Булат Мусин (Казан), Радик Сәлахов (Әлмәт) һәм Ранис Гыйләҗетдинов (Чаллы) танылды. Командалар бәйгесен исә Әлмәт егетләре отты. Лаеш – икенче, Чаллы исә өченче булды. Быел исә фаворит дип күпләр Лаеш егетләрен атый. Ике бәйге арасында аларның командасы тагын да ныгыды. Хәзер бу район данын Радик Сәлахов яклый. Балык Бистәсендә үсеп, озак еллар Казанның Яңа Савин районы өчен бил алышкан Илмир Төхфәтуллинның да Лаеш командасына күчкәне билгеле булды. Икесенең дә газетабыз бәйгесендә берничә җиңүе бар. Әмма Теләче, Әлмәт һәм Чаллы егетләренең дә биле нык, беләге көчле.

60 нчы ТУРНИР
17–18 ФЕВРАЛЬ, КАЗАННЫҢ «АК БАРС» КӨРӘШ САРАЕ

Татарстан Көрәш федерациясе | МИНСПОРТ Татарстан Спорт министрлыгы | ВТ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе

АЧЫЛУ ТАНТАНАСЫ 17 ФЕВРАЛЬ КӨННЕ ИРТӘНГЕ СӘГАТЬ 10га БИЛГЕЛӘНГӘН

Балтачка ерак әле

Шунысы кызык: Лаеш командасының әле бер мәртәбә дә Муса Җәлил бәйгесе Кубогына ия булганы юк иде. Соңгы елларда аны икешәр мәртәбә Әлмәт һәм Теләче егетләре яулады. Аңа кадәр Зәй командасы өч мәртәбә рәттән отты. Гомумән алганда, Әлмәт егетләренең 8 җиңүе бар. Чаллы командасы Кубокны 9 мәртәбә яулады. Иң алда исә Балтач бара. Бу район егетләре газетабыз бәйгесен 13 мәртәбә отты. Соңгы җиңүне алар әле 2005 елда ук яулаган. Былтыр, мәсәлән, алар, 10 нчы урынны алган. «Аның каравы бездә читтән чакырылган бер генә көрәшче дә юк. Башка районнарның берсе дә мондый күрсәткеч белән мактана алмый», – дип горурлана бу район көрәшчеләре.

Заманында Балтачтан Айдар Хәйретдинов Муса Җәлил бәйгесендә үз авырлык категориясендә 10 тапкыр җиңү яулады. Аны якыннан белгән кешеләр әйтә: тагын да күбрәк булдыра ала иде. Әмма эш-мәшәкатьләре аркасында келәмнән иртәрәк китәргә туры килде. Дөрес, үзе булганына шөкер итә, аның ничек итеп бил алышканын исә әле дә үрнәк итеп телгә алалар. Ә бәйгедә иң күп җиңү яулаган кеше – Чаллыдан Айрат Гыйлаев. Ул газетабыз турнирында 12 мәртәбә чемпион булды. Айратның батырлыгын тиз генә кабатлый алмаячаклар әле. Иң күп җиңү яулаган көрәшчеләр исемлегендә 9ар җиңүле өч кеше бар. Болар – Теләчедән Раил Нургалиев, келәмнән инде күптән киткән Балык Бистәсе егете Илнар Әхмәтҗанов һәм моннан өч ел элек вакытсыз вафат булган Әлмәт пәһлеваны Ильяс Галимов.

Ярты гасырдан артык тарихы булган бәйгедә элеккеге елларның җиңүчеләре зурлана, бакыйлыкка күчкән батырлар искә алына. Яшь егетләр көрәшнең үткәнен белеп торсын, батырлыкның мәгънәсен яхшырак аңласын өчен. Муса Җәлил исемен йөртүче ике турнир арасында әлеге төшенчәнең мәгънәсе тагын да артты.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

ТЫҢЛАРСЫҢМЫ ИКӘН ХИСЛӘРЕМНЕ?

Мөнәсәбәт

Россиядә психолог һәм психотерапевтларга мөрәҗәгать итүчеләр саны 7 тапкыр арткан. 2022 елгы статистик саннар шул хакта сөйли. Сентябрь – октябрь айларында моң-зарларын белгечләр белән уртаклашучылар аеруча күп булган.

Кемгә нинди ярдәм кирәк?

Бер яктан, бу аңлашыла да инде. Көз айларында халыкта киеренкелек хисе чиктән ашкан иде бит. Ярдәм сорап белгечкә мөрәҗәгать итүчеләрнең 82 проценты хатын-кызлар булган. 26–25 яшьтәгеләр өлешенә психологик консультацияләрнең 53 проценты туры килгән. Тагын 17 проценты 18–25 яшьлекләр өлешенә карый.

Сораштыруны оештырган төркемнең мәгълүматларына караганда, яшьләр психологларга үзләрен табу, карьера, үсеш, гаилә һәм яшькә бәйле кризисны җиңүдә ярдәм сорап килә. Өлкәнрәкләрне исә психосоматик проблемалар, бала һәм ата-ана мөнәсәбәтләре, эштән арулар борчый.

Өлкән буынның исә зарланырга вакыты юк. Белгечләр әйтүенчә, алар хезмәт, спорт, физик активлык бәрабәренә эмоцияләрен җиңәргә өйрәнгән. Әмма проблемаларны хәл итмичә, аннан качарга омтылу хәерлегә илтмәскә дә мөмкин. Еш кына бу тормыштан ямь тапмау, тулы канлы тормыш белән яшәмәү, элеккеге активлык югалуга да китерә, дип кисәтә белгечләр.

Белгечләр психологка килүчеләрне дүрт төркемгә бүлеп карый. Беренче төркемне рухи сораулар кызыксындыра. Икенче төркемгә караганнарны шәхси, гаилә сораулары, төрле низаглар һәм аңлашылмаучанлыклар борчый. Өченче төркем – карьерасы өчен кайгыручылар, бу җәһәттән үзләрен эзләүчеләр. Дүртенчеләр исә – психосоматик тайпылышлардан арынырга теләүчеләр.



Илдар Мөхәммәтҗанов

Мөрәҗәгать итәләрме?

Психологик ярдәм сораучыларның артуын практик психолог Зөһрә Кәримова да сизгән.

– Күп кешеләр психологка йөри башлады. Әлбәттә, аларның безгә китергән сәбәпләре дә төрле. Иң еш очрый торганнары – курку, борчылу, балачак травмалары. Мин хатын-кызлар белән үз-үзеңне табу, акча эшләү, үз эшеңне башлау кебек темаларга эшлим. Шулай ук хезмәт урыныннан ару, төшенкелек, хәзерге тормышларыннан канәгать булмаган очраклар да була, – ди ул. – Хәзер бит һәр кешенең үз психологы бар. Бу – үзенә күрә бер тренд та. Бер яктан, бу начар нәрсә дә түгел. Икенче яктан карасаң, кешеләр артык тирәнгә керүдән курка. Шуңа күрә аларның психологка мөрәҗәгать итүләре дә ярты юлда төгәлләнми кала. Ил-көндәге вазгыять тә күпләргә йогынты ясый. Тынычлык таба алмаучылар күп.

– 2018 елдан бирле психолог булып эшлим. Хәзер психологларга мөрәҗәгать итүчеләр чыннан да күп. Нинди сораулар белән киләләр дигәннән, алар әллә ни үзгәрми: шәхси чикләр кую, «юк» дияргә өйрәнү, үзеңне беренче урынга чыгару, ышаныч арттыру. Менә-менә килеп чыккан ихтыяҗларның берсе – үзеңне эзләү. Күпләр рухи яктан үзләренең кем булуын аңларга тели, үз миссияләрен эзли. Хәзер бит үзеңә эшләү, үзмәшгульлек популяр. Психологларга һәр икенче кеше балачак травмаларыннан зарланып килә, – ди психология фәннәре магистры Чулпан Нигъмәтҗанова.

Ни өчен зарларны психологка сөйләү популярлашты соң? Бу мода артыннан куумы, әллә инде замана таләбеме? Кешенең эч серләре белән бүлешерлек кешеләре юкмы әллә? Болар да сәбәпләр рәтендә торадыр, билгеле.

Психолог Николай Литвинов әйтүенчә, элегрәк стресс күрсәткече хәзерге заман кешесенеке кебек үк югары булмаган.

– Бердән, кешенең төп ихтыяҗлары канәгатьләндерелгән иде. Әйтик, дәүләт биргән йорт-җире бар, кечкенәме-зурмы – мөһим түгел. Түбәсез калу куркынычы янамый. Эш белән дә тәэмин итеп торучы дәүләте бар. Даими тотрыклы керем килеп тора. Кешеләр куркыныч тоеп яшәмәгән, – ди белгеч. – Икенче сәбәп – медиамохиттәге негативның күплеге. Позитив һәм ышаныч тудыра торган яңалыклар юк. Стресс дәрәҗәсенең түбән булуы киләчәккә ышанычтан да килә иде. Бу психологларга ихтыяҗны бермә-бер киметә. Хәзер психологлар күп булганга күрә психологларга йөрүчеләр дә күп, диләр. Бу дөрес үк түгел инде. Ихтыяҗ һәм сорау булганда тәкъдим дә бар. Хәзер психологлар хәл итә торган проблемалар исемлеге дә зуррак.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Сүз уңаеннан

Ни гаҗәп, Россиядә әлегә кадәр психологик ярдәм турында Федераль закон юк. Гәрчә халык турында кайгыртучылар бу хакта өч дистә еллап сөйләп торса да. Менә, ниһаять, сәгате суккан бугай. Россиядә психологик ярдәм турында закон кабул итәргә вакыт, дип саный Дәүләт Думасы депутатлары. Аңлатуларына караганда, хәзер бу аеруча әһәмиятле, чөнки җәмгыятьтә борчу-депрессия халәтләре артканнан-арта бара.

Бу җәһәттән депутатлар закон проектын әзерли. Шулай итеп, илдә психологларның профессиональ хезмәтен булдырмагайлары. Ул хезмәт аеруча яшьләр һәм балалар белән эшләүгә йөз тотачак. Әлбәттә, башкалар да файдалана алачак.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Ганиевлар гаиләсе,

НУРИЕВ Ранис Мәксут улы

вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең хатыны – Нуриева Елена Александровнаның, кызлары – Светлана һәм Элинаның авыр кайгысын уртаклаша.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5322 данә
Гомуми тираж – 15277 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 218

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәширият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+